“Раслыйм”
Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
“Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең
җир биләмәләреннән файдалану һәм
төзелеш кагыйдәләре комиссиясе рәисе

______________________И.Ф. Рәхимов

2019 елның 7 нче августы
№ 12

Ачык тыңлаулар буенча
**Нәтиҗә**

ТР ЧМР “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге башлыгының “Җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында”гы 2019 елның 16 нчы июлендәге 14 номерлы карары нигезендә, ачык тыңлаулар 05.08.2019 ел, 10.00 сәгатьтә Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының зур залында түбәндәге адрес буенча узды: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 йорт.

**Ачык тыңлауларда каралган мәсьәләләр:**

Чистай шәһәр прокуратурасының 2019 елның 10 нчы июнендәге, 02-08-03-2019 номерлы күрсәтмәсе буенча, кадастр номеры16:54:180201:31, мәйданы 1936 кв.м., адресы: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Вәлиев урамы, 27-е йорты, “Юл буе сервисы объектлары” ПК-2 “III куркыныч класслы җитештерү-коммуналь объектлар зонасы”төзелеш зонасында җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча.
**Карар ителде:**
1. Кадастр номеры 16:54:180201:31, мәйданы 1936 кв.м. булган җир кишәрлегенә карата өстәмә документлар һәм мәгълүмат җыю зарурлыгына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Вәлиев урамы, 27 нче йорт адресы буенча ачык тыңлауларны бер айга кичектерергә.
2. Әлеге нәтиҗәне ТР Хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Комиссия сәркатибе: ______________________М.Р.Бибишев